Tatar16.ru

Мифтахетдин Акмулла

(1831 – 1895)

*« Сатмас егет илен алтын көмешләргә,*

*Әгәр югалтмаса вөҗданын.*

*Алтынны ул чүпкә санар,*

*Иң кыйммәтле күрер Ватанын »*



Tatar16.ru

- *Мифтахетдин Мөхәммәдъяр улы Акмулла (26 декабрь 1831, Дүсән, Бәләбәй өязе, Уфа губернасы — 27 октябрь 1895, Троицки–Зылатаус юлы) — шагыйрь һәм мәгърифәтче. Татарһәм казакъ телләрендә иҗат иткән .*
- *Акмулла хәзерге Башкортстан Республикасы Бишбүләк районының Дүсән авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Атасы Мөхәммәдъяр үлгәч, анасы Өммегөлсем күрше*
- *башкорт авылына — Туксанбайга кияүгә чыга. Башкортстан ягы Акмулланы этник башкорт итеп күрсәтергә омтыла. Шуның өчен аларга үги атасы Камалетдинне Акмулланың чын атасы итеп күрсәтү кирәк. "Дүсән вер сиясе" әдипнең әсәрләренә, аның белән яхшы таныш Риза Фәхретдин, Акмулланың*

- шәкерте Дусмаил Качкынбаев истәлекләренә таяна.
- Акмулла Туксанбайда башлангыч белемне ала. Аннары Мәнәүзтамак, Әнәч, С тәрлебаш мәдрәсәләрендә белем
өсти. Стәрлебашта шагыйрь Шәмсетдин Зәкидән дәресләр ала,
соңрак Троицки мәдрәсәсендә укый. Җәйләрен казакъ ягына чыгып, балалар укыта.
- Акмулла төрле урыннарда яши, эшли. Уку–язу, белем

Tatar16.ru

- бирүдән тыш, балта остасы, тимерчелек һөнәре белән дә шөгыльләнә; матур моңлы тавыш белән җырлый да; тыңлаучыларны мавыктырырлык итеп сөйли дә, шигырьләр дә укый.
- Акмулланың безгә билгеле иҗат мирасы әлләни зур түгел. Шагыйрьнең җыентыклары Казанда

Tatar16.ru



- бернигә мәртәбә нәшер ителгән (1892, 1904, 1907 елларда). Акмулла әсәрләре мәрсия, мәдхия, робагый, шигъри хат, газәл, мөнәҗәт жанрларында иҗат ителгән. Шагыйрьнең иң беренче басылган зур әсәрләреннән берсе – «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» (1892) Акмулланы барлык төрки телләрдә сөйләшүче укымышлыларга таныта.
- Акмулланың әсәрләре тирән
- һәм фәлсәфи эчтәлекле, поэтик эшләнешләре камил булу белән аеруча игътибарга лаек. Ул чын мәгънәсендә шигырь остасы, XX гасыр мәгърифәтчелек әдәбияты тарихында тирән эз калдырган, шигырь мәктәбе тудырган әдипләрнең берсе һәм күренеклесе.



Tatar16.ru

- *Акмулланың үлеме көтелмәгәндә һәм үкенечле була. Ул 1895 елның 27 октябрендә каршы төндә Троицкидан Зылатауска баргаында, Мияс заводыннан ерак түгел юлбасарлар тарафыннан үтерелгән. Миәстә әдип кабере өстендәге ташка гарәпчә текст уеп язылган. Татарчага юлга-юл тәрҗемәсе:*
- “Шаһидләрчә үтерелгән, 1313 елда сигезенче җөмади-әл-үләда, җомга көнне кичен;
- Акмулла исеме белән билгеле мелла Мифтахетдин, нәсел буенча атасы Мөхәммәдъяр хәлфә, тәрбия буенча атасы Камалетдин. Тәмам, бетте”

Tatar16.ru

- *Күрсәтелгән дата 1895 елның 26 октябрьдән 27 гә каршы төнгә туры килә. 1980 елда иске, ишан Зәйнулла Рәсүлев куйдырган ташны Уфадан килгән делегация алып ташлый һәм аның урынына "Туксанбай" версиясен куәтләгән язулы мәрмәр плитә куя.*